ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**Чистай шәһәре**

**24.03.2025** **№ 130**

Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының муниципаль норматив хокукый актларына экспертиза ясау турында» 2017 елның 07 апрелендәге 265 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башкарма комитеты кабул ителүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 202 елның 11 июнендәге 170-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының муниципаль норматив хокукый актларына экспертиза ясау турында» 2017 елның 07 апрелендәге 265 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Гомуми нигезләмәләр 1 бүлегендә:

1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- Әлеге нигезләмә муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру тәртибен билгели, эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектлары өчен артык бурычлар, тыюлар һәм чикләүләр кертә торган яисә аларны кертүгә этәрә торган нигезләмәләрне, шулай ук эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлек субъктларының һәм җирле бюджетларның нигезләнмәгән чыгымнарын барлыкка китерүче нигезләмәләрне ачыклау максатларында уздырыла.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (http://chistopol.tatar.ru/) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

4. Карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов